**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Төги авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 176** **«07» август 2020 ел**

**"Физик затлар мөлкәтенә салым турында"**
**2014 елның 14 ноябрендәге 134 номерлы**
**Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге**
**Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 14 ноябрендәге 134 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 10 сентябрендәге 170 номерлы, 2018 елның 29 октябрендәге 113 номерлы, 2019 елның 21 мартындагы 129 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» сүзен һәм «дача» сүзен төшереп калдырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Төги авыл җирлеге башлыгы** **Т.В.Попова**